**СОВЕТ АЛАН-БЕКСЕРСКОГО СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ ВЫСОКОГОРСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН**
422723, Республика Татарстан, Высокогорский район
с. Алан-Бексер, ул. Центральная, 19

**РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН БИЕКТАУ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ АЛАН-БӘКСӘР АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ СОВЕТЫ**
422723, Татарстан Республикасы, Биектау районы,
Алан-Бәксәр авылы, Үзәк. ур, 19

Тел./факс: +7(84365) 63-9-51, e-mail: AlayB.Vsg@tatar.ru

---

**РЕШЕНИЕ** **КАРАР**
**22 июль 2019 ел** **№ 176**

## Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы Алан-Бәксәр авыл җирлеге тарафыннан шәһәр төзелеше эшчәнлеге өлкәсендә җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итү буенча вәкаләтләрнең бер өлешен Кабул итү турында

“Җирлекләрнең генераль планнарын, җирдән файдалану һәм төзелеш кагыйдәләрен эшләү һәм раслау буенча вәкаләтләрне тапшыру турында Биектау муниципаль районы башкарма комитеты һәм Биектау муниципаль районы составына керүче авыл җирлекләре башкарма комитетлары арасында килешүләрне раслау турында” Биектау муниципаль районы Советының 30.05.2009 елдагы 300 номерлы карары нигезендә, «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законга, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы законына, «Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы Алан-Бәксәр авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Уставына таянып, Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы Алан-Бәксәр авыл җирлеге Советы,

**КАРАР БИРӘ:**

1. «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 14 статьясындагы 3 һәм 4 өлешләре нигезендә шәһәр төзелеше эшчәнлеген гамәлгә ашыру өлешендә вәкаләтләрнең бер өлешен Кабул итәргә.

Кабул ителә торган вәкаләтләрне гамәлгә ашыру предметы булып

- җирлекнең генераль планын раслау;
- җирдән файдалану һәм төзелеш кагыйдәләрен раслау;
- җирлекләрнең шәһәр төзелеше проектларының җирле нормативларын раслау тора.

2. Алан-Бәксәр авыл җирлеге башкарма комитеты белән шәһәр төзелеше эшчәнлеген гамәлгә ашыру буенча Биектау муниципаль районы башкарма комитеты арасында Килешү төзергә.

3. Әлеге Карарны имзалау өчен Алан-Бәксәр авыл җирлеге башлыгына җибәрергә.

4. Әлеге карарны авыл җирлегенең мәгълүмат стендларында, Биектау муниципаль районының http://vysokaya-gora.tatarstan.ru/ рәсми сайтында һәм Татарстан Республикасы http://pravo.tatarstan.ru/ хокукый мәгълүмати рәсми порталында урнаштыру юлы белән халыкка игълан итәргә.

5. Әлеге карар рәсми басылып чыккан көненнән үз көченә керә.

Совет Рәисе
Авыл җирлеге башлыгы З.Р.Гарифуллина